Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12.11.2020 Менделеевск ш. № 648

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 октябрендәге 617 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә; Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе; «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XП номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 октябрендәге 617 номерлы карары белән расланган «2021 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программа паспорты» бүлегенең «Көтелә торган нәтиҗәләр» пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында татар милләте балаларын татар телендә укыту һәм тәрбияләүне колачлау өлеше 14 процент тәшкил итәчәк.

- Гомуми белем бирү оешмаларында татар милләте балаларын татар телендә укытуны һәм тәрбияләүне колачлау өлеше 15 процент тәшкил итәчәк.
- Гомуми белем бирү оешмаларында рус милләтендәге балаларны туган рус телендә укытуны колачлау өлеше 100 процент тәшкил итәчәк.»

1.2. «Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар планы» бүлеген түбәндәге пункт белән тулыландырырга:

VII. Программаның Индикаторлары

Программаның индикаторлары булып тора:

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | | Индикаторлар әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | 2020 ел (бәяләмә) | 2021 ел | 2022 ел |
| Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында татар милләте балаларын татар телендә укыту һәм тәрбияләүне колачлау өлеше, процентлар | 12 | 13 | 14 |
| Гомуми белем бирү оешмаларында татар милләте балаларын татар телендә укыту һәм тәрбияләүне колачлау өлеше, процентлар | 13 | 14 | 15 |
| Гомуми белем бирү оешмаларында рус милләте балаларын туган рус телендә укытуны колачлау өлеше, процентлар | 100 | 100 | 100 |

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендә www.mendelevsk.tatar.ru сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. И. Ямалеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников